МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.07.2023 г. Казань № 1590

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.10.2019 № 2126 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.10.2019 № 2126 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр М.М.Миңнуллин

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән расланган
19.07.2023 № 1590

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында»Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 31.10.2019 № 2126 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр.

1. Пункт 1.1 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларының проектларында коррупцияген факторларны ачыклау һәм аларны алга таба бетерү максатларында, әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актларының проектларына (алга таба - актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза уздыру процедура тәртибен билгели.».

2. Пункт 1.5 түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә, шул исәптән бәйсез экспертиза үткәргәндә, ачыкланган коррупцияген факторлар Министрлыкның структур бүлекчәсе тарафыннан юкка чыгарыла, әлеге акт аның инициативасы белән чыга (акт проектын төзү өчен җаваплы) (алга таба – төзүчесе).».

3. Пункт 2.2 беренче абзацтагы түбәндәге сүзләрне «әлеге актны кабул итүнең инициаторы булган (акт проектын эшләп чыгару өчен җаваплы) структур бүлек җитәкчесе тарафыннан» «төзүчесе тарафыннан» сүзләре белән алыштырырга.

4. Пункт 2.3 беренче абзацтагы «вазыйфаи зат» сүзләреннән соң «акт (акт проекты) кабул ителгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча» сүзләрне өстәргә.

5. Пункт 2.4 түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен нигез.».

6. Пункт 2.5 түбәндәге сүзләрне «әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага җибәргән затка» «төзүчесенә» сүзе белән алыштырырга.

7. Пункт 2.6:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар күрсәтелгән бәяләмәне алганнан соң өч эш көне эчендә төзүче акт проектын эшләп бетерә һәм эшләп бетерелгән проектны вазифаи затка яңадан карауга җибәрә.»;

икенче абзацта түбәндәге сүзләрне «аның инициативасы буенча акт кабул ителгән структур бүлекчә җитәкчесе» «төзүчесе» сүзләре белән алыштырырга.

8. Пункт 2.7 түбәндәге сүзләрне «акт проектын эшләп чыгару өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе,» «төзүчесе» сүзләре белән алыштырырга.

9. Пункт 3.3 «Вакыт чикләрендә» сүзләреннән соң «,акт проекты коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен урнаштырылган вакытка,» сүзләре белән тулыландырырга, «акт (акт проекты) әзерләү өчен җаваплы Министрлыкның структур бүлекчәсенә» сүзләрен «төзүчесенә» сүзләре белән алыштырырга.

10. Пункт 3.7 яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Әгәр актта коррупцияген факторлар ачыкланса, төзүче бәяләмәне теркәгән көннән алып өч эш көне эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аны үз көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.».

11. Пункт 4.4. дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзтезмәсен «Татарстан Республикасы Рәисе» дип алмаштырырга.

12. Пункт 4.5 түбәндәге сүзләрне «проектны эшләп чыгару инициаторы булган структур бүлекчә» «төзүче».

13. Пункт 4.6 «актлар проектлары,» сүзләреннән соң «төзүче тарафыннан билгеләнә торган,» дип тулыландырырга.

14. Пункте 4.7 түбәндәге сүзләрне «проектны эшләп чыгару инициаторы булган структур бүлекчә тарафыннан» «төзүче тарафыннан» дип алыштырырга.

15. Пункт 4.8 икенче абзацта «актны (акт проектын) эшләп чыгаручы җаваплы зат» «төзүче тарафыннан» дип алыштырырга.